**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Юлсубинского сельского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
Индекс 422669 с.Юлсубино ул.Татарстан дом 56а телефон

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Юлсубино авыл җирлеге Башлыгы**
индекс 422669 Юлсубино авылы
Татарстан ур. 56а йорт
телефон

Тел.: (84361) 30223, факс: (84361) 30223, эл.адрес: Uls.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

от 03.11.2022 года Юлсубино №1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Юлсубино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың беренче этабын 2022 елның 22 ноябрендэ 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың икенче этабын 2022 елның 24ноябрендэ11 сәг. 00 минутка билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
4. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең Юлсубино авылы торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сәләтсез гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан кала ) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

1. Юлсубино торак пунктында урам утларын ремонтлау

2.Юлсубино авылы торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын ремонтлау
3. Юлсубино авылында яшәүчеләргә су алу, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау
4.Халык күпләп ял итә торган урыннарны(парклар, скверлар,спорт мәйданчыклары һәм халык күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияне төзекләндерү.
5. Юлсубино авылында кышкы һәм җәйге юлларны карап тоту
6. Юлсубино авыл торак пунктында коммуналь калдыклар өчен контейнер мәйданчыгы төзү һәм контейнерлар сатып алу

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Юлсубино авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56а йорт, Ямаш авылы һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов